*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*№ 2*

*Октябрь , 2025 ел*



**Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар**

## «Бер күрешү- үзе бер гомер!»

***Бер күрешү – үзе бер гомер, ди***
***Күрештегез бүген биредә.***
***Ходай насыйп итте бәйрәм көнне***
***Җыелышып монда килергә.***
***Таныш сукмак, таныш урамнардан***
***Салмак кына атлап, җай гына.***
***Өлкән буын килә, әйтерсең лә***
***Яшьлегенә кайта аз гына...***
***Күп тапкырлар үтелгән бу сукмактан,***
***Әле генә кебек, кичә генә...***
***Гомер үткән: кемгә 60, 70, 80,***
***Йөрәк кенә һаман унсигездә.***
***Таныш йөзләр, якын хезмәттәшләр***
***Бәйрәм табынына бүген килгән.***
***Хатирәләр бик күп, сөйләр сүзләр...***
***Истәлекләр, үзең генә белгән...***





***Өлкән буын ихтирамга лаек,***
***Безгә –маяк,тормыш юлыбызда.***
***Сәламәтлек, шатлык, ак бәхетләр***
***Телибез без бүген барыгызга.***
***Бала, оныкларга кирәк булып***
***Кадер, хөрмәт кенә бары тоеп.***
***Яшәгезче әле, картаймагыз,***
***Яшь бара бит, диеп, уфтанмагыз.***
***Сез булганда әле, без – бәхетле.***
***Нур бөркелә сезнең йөзегездән.***
***Бәйрәм сәламе итеп, җылы сүзләр***
***Һәм теләкләр кабул итегез бездән!***

## «Бакчабызда өлкәннәр көне»























Өлкән буын вәкилләренә хөрмәтебез һәм рәхмәтебез бик зур. Шул уңайдан «Балачак» балалар бакчасында зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары катнашында бик күңелле итеп өлкәннәр көне уздырылды. Әлеге чарага балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның кадерле кешеләре - әби - бабайлары чакырулы иде. Бүгенге тыңгысыз көннәрдә безнең якты, матур киләчәгебез өчен тырышкан якыннарыбызны сөендереп, оныклары матур шигырьләр, эчтәлекле җырлар, биюләр бүләк иттеләр. Балалары белән берлектә төрле уен-ярышларда катнаштылар. Өлкәннәребезнең йөзләрендә елмаю күрү һәммәбез өчен дә куаныч.

Хөрмәтле өлкәннәребез, батырлыгыгыз,сабырлыгыгыз өчен һәммәгезгә дә зур рәхмәт!Гел шундый якты йөзле, тәмле сүзле булып балаларыгызны,оныкларыгызны сөендереп, озак яшәгез. Кояшлы, якты, гомер юлыгыз бәхетле, саулыгыгыз нык булсын .

***Балалар бакчасында эшләп, лаеклы ялда булучы өлкәннәребезнен хәлләрен белеп, бәйрәм белән котладык .***







# «Көз бүләкләре»



Балалар бакчасында балалар һәм ата- аналар белән берлектә «Көз бүләкләре» күргәзмәсе оештырдык.

Мондый күргәзмәне үткәрү инде традициягә әверелде, шуңа күрә балалар һәм ата - аналар бик теләп катнашалар. Бөтен кул эшләре, чәчәк бәйләмнәре, композицияләр оригиналь, уникаль һәм тырышлык белән ясалган. Барлык катнашучыларга кабатланмас һөнәрләре өчен рәхмәт белдерәбез.



Балалар бакчасы тарафыннан балалар грамоталар белән бүләкләнделәр.

# Безнең уңышлар




*Хөрмәтле тәрбиячебез Гафурова Рафия Ансар кызын Арча муниципаль районы башлыгы МАКТАУ ГРАМОТАСЫНА лаек булуы белән чын күңелдән котлыйбыз. Уңышлар дәвамлы булсын.*




*Барлык акциядә катнашучыларга – тәрбиячеләргә, балаларга һәм аларның әти -әниләренә тырышлыклары өчен рәхмәт.*



*ТР Рәисе идарәсенең баш киңәшчесе Лидия Фаварисовна безнең балалар бакчасы эшчәнлеге белән танышты, югары бәя бирде*




*«Эколяталар калдыкларны аерып җыю һәм материалларны кабат файдалану яклы» Безнең балалар бакчасында тәрбияләнүче Исхакова Зәлия «Эколяталар калдыкларны аерып җыю һәм материалларны кабат файдалану яклы» темасына Бөтенроссия рәсем ясау конкурсында катнашты һәм сертификат белән бүләкләнде. Табигатьне саклагыз һәм исегездә тотыгыз-безнең һәркайсыбыз да Җирне коткарып калу өчен уз өлешен кертә ала!*



*Воспитанники нашего детского сада Халиуллин Райнур и Тухбатуллина Саида приняли участие в Фестивале чемпионов Всероссийского физкультурно-спортивного комплекса «Готов к труду и обороне»(ГТО) в Республике Татарстан «ИГРЫ ГТО »среди дошколят Арского муниципального района, заняли 3 место.Молодцы, поздравляем.Желаем дальнейших успехов .*

## «Курчак театры бездә кунакта»







Балалар бакчасында Яр Чаллы шәһәренең «Алина» курчак театры «Веселый детский сад» исемле музыкаль әкияте белән кунакта булды. «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие» әкиятенә нигезләнеп эшләнгән. Белмәгән кешеләр белән сөйләшмәскә, ишек ачмаска, куркынычсызлык кагыйдәләренә басым ясалган. Җырлы-биюле әкият балалар күңеленә хуш килде, әкият дөньясына чумдырды.

# « Әтиләр көне »

Октябрьнең өченче якшәмбесе – Әтиләр көне! Шул уңайдан балалар бакчасына җаваплы эштә хезмәт куючы әтиләрне кунакка чакырдык.

Биектау районы буенча Эчке эшләр бүлегенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлекчәсенең җитәкчесе полиция майоры - Асадуллин Айрат Ринат улы.

Арча районы электр челтәре компаниясе хезмәткәре - электромонтёр Төхбатуллин Рөстәм Солтан улы.

Төзелеш буенча шәхси эшмәкәр - Мөхәмәтҗанов Раиф Рөстәм улы.

Алар балаларны үзләренең һөнәрләре белән таныштырдылар,төпле киңәшләрен бирделәр. Очрашу ахырында кунаклар балаларга киләчәк тормышларының имин булуын,бәхетле мизгелләрдән генә торуын теләделәр. Балалар аларның киңәшләрен тотып, үзләренә кирәкле һөнәр сайларлар. Нинди генә һөнәр сайласалар да, иң беренче чиратта, һәр кешедә эш сөючән, тырыш, намуслы булу, башкаларны хөрмәт итә белү сыйфатлары булырга тиеш. Барыгызга да ныклы сәламәтлек,гаилә бәхете,тыныч – имин көннәр телибез.
















*Әти – гаилә башлыгы*
*Дөньяда иң яхшысы*
*Дус та ул, укытучы да*
*Һәм безнең тән сакчысы*

*Әтиләр безнең өчен*
*Гаиләдә иң нык терәк*
*Әтиләрне һәрвакыт*
*Хөрмәт итәргә кирәк*

*Бүген синең бәйрәмең*
*Кадерле әтиебез!*
*Исәнлек-саулык сиңа*
*Бәхет-шатлык телибез*



# «Бумбатл» акциясендә актив катнаштык»

13 нче октябрьдән 17 нче октябрьгә хәтле безнең балалар бакчасында макулатура җыю буенча «Бумбатл» акциясе узды. Акция алдыннан тәрбиячеләр әңгәмәләр үткәрделәр, анда балаларга һәр кешенең урманнарны, экологияне һәм планетабызның табигый матурлыгын саклау эшенә өлеш кертә алуы турында сөйләделәр. Мәсәлән, һәркем макулатура тапшыра ала-бу кечкенә булса да, табигатьне саклауга мөһим өлеш кертү. Акциянең төп максаты-әйләнә-тирәлекне саклауга һәм ресурсларны саклауга омтылыш, табигатькә сакчыл караш. Акциядә барлык балалар, аларның әти-әниләре катнашты. Иң күп макулатура алып килүче балаларга грамота һәм бүләкләр тапшырылды.

Барлык акциядә катнашучыларга – тәрбиячеләргә, балаларга һәм аларның әти-әниләренә тырышлыклары өчен рәхмәт.






# Туган көн белән котлыйбыз!

Октябрь аенда кечкенәләр төркеменә йөрүче егетебез: **Азизуллои Әмин** һәм зурлар төркеменә йөрүче егетебез **Асадуллин Азамат туган** көннәрен билгеләп үттеләр. Балаларга сәламәт, озын гомерле, бәхетле, акыллы, тәүфыйклы булып, әти-әни тигезлегендә үсүләрен телибез.








***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Гафурова Р.А., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Хөсәенова Р.Н, Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*